ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

15 03 2024 г. № 276

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 3 августындагы 504 номерлы карары белән расланган күчемсез милек объектларына адреслар бирү һәм гамәлдән чыгару буенча авыл җирлекләре тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 5 февралендәге 124 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Түбән Кама муниципаль районының Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 3 августындагы 504 номерлы карары белән расланган күчемсез милек объектларына адреслар бирү һәм гамәлдән чыгару буенча Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлеге тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) кәгазьдә гариза бирелгән очракта - гариза кергән көннән соң 10 эш көненнән дә артык булмаган вакытта;

б) электрон документ формасында гариза бирелгән очракта - гариза килгән көннән соң 5 эш көне эчендә».

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны тәэмин итәргә һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

«Исполнительный комитет Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан» МКУ * «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ *
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874